СОВЕТ КУГУШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КҮГЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**06 март 2024 ел** Күгеш авылы **№166**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җир эшләрен башкаруга рөхсәт бирү буенча вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлегенә тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 4 өлешенә ярашлы рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге Советы **карар итэ**:

1.Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлегенә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының “Күгеш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җир эшләрен башкаруга рөхсәт бирү буенча вәкаләтләренең бер өлешен тапшырырга.

2. Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге башкарма комитетына Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә.

3.Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру ел саен Күгеш авыл җирлеге бюджетыннан Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар хисабына башкарыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Күгеш авылы, Мәктәп яны урамы, 1а йорт (администрация бинасы) адресы буенча мәгълүмат стендында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет Рәисе:** **А. А. Гатауллин**